| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 август г.Казань № 724

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел, 14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011

ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы; 2016 ел, 26 август, 593 нче; 2018 ел, 8 август, 644 нче; 2018 ел, 31 октябрь, 976 нчы; 2018 ел, 18 декабрь, 1159 нчы, 2018 ел, 29 декабрь, 1299 нчы, 2020 ел, 17 февраль, 120 нче, 2020 ел, 15 апрель, 288 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы:

Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә алкогольле продукцияне һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуны лицензияләү (01.21[*]);

этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм әйләнеше өлкәсендә җайга салу (03.05.01*);

алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.05.01*);

кулланучылар хокукларын тормышка ашыру, тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны гамәлгә ашыру (03.06*).»;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә функцияләрен тормышка ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.07*);

---

[*]Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы нигезендә кодны билгеләү.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыруны гамәлгә ашырганда (01.01*);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән эчке товар базарының аерым товарлар, хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителеше өлкәсендә җайга салу функциясен тормышка ашырганда (03.05*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру функцияләрен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен тормышка ашырганда (01.17*).»;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә функцияләрен гамәлгә ашырганда  (04.10*);

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин